РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ГЛАВА НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА И ГОРОДА НУРЛАТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ҺӘМ НУРЛАТ ШӘҺӘРЕ БАШЛЫГЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

№ 113

«17» сентябрь 2024 ел

«Кондырчанефть» акционерлык җәмгыятенең Әдиләк нефть ятмасында 8709,8725 номерлы скважиналар челтәрен төзекләндерү» объекты буенча территорияне планлаштыру проекты. «Кондырчанефть» акционерлык җәмгыятенең Әдиләк нефть ятмасының нефть үткәргечләрен төзү. БГ no 8709 дан БГ-8656 га кадәр нефть үткәргечен төзү. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге чикләрендә урнашкан 8725 нче БГ дан алып 8649 нчы БГ га кадәр нефть үткәргеч төзү" проектын карау буенча гавами тыңлауларны билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 - 46 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Нурлат муниципаль районы Советының 2021 елның 23 мартындагы 53 номерлы Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында гавами тыңлаулар, иҗтимагый фикер алышулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында карары белән расланган Нигезләмә нигезендә

КАРАР ИТТЕ:

1. «Кондырчанефть» акционерлык җәмгыятенең Әдиләк нефть ятмасында 8709,8725 номерлы скважиналар челтәрен төзекләндерү», «Кондырчанефть» акционерлык җәмгыятенең Әдиләк нефть ятмасының нефть үткәргечләрен төзү. 8709нчы БГ дан БГ-8656 га кадәр нефть үткәргеч төзү. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге чикләрендә урнашкан 8725 нче БГ дан алып 8649нчы БГ га кадәр нефть үткәргеч төзү" объекты буенча территорияне планлаштыру проектын карау буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Гавами тыңлауларны үткәрүне оештыручы итеп Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеген билгеләргә тәкъдим итәргә.

3. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

3.1. гавами тыңлаулар үткәрү вакыты – 07.10.2024 ел сәг. 10.00да;

3.2. үткәрү срогы-әлеге карар басылып чыккан көннән алып гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр кимендә бер ай һәм өч айдан да артмаган;

3.3. үткәрү урыны-ТР Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының кече залы, ул түбәндәге адрес буенча урнашкан: ТР, Нурлат ш., Совет ур., 117 йорт;

3.4. фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр бирелә торган, чыгыш ясау хокукы булган гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелә: Татарстан Республикасы, Нурлат ш., Совет ур., 117 йорт (архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге), эш көннәрендә-8.00 дән 17.00 гә кадәр;

4. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегендә халык тыңлауларына чыгарыла торган мәсьәлә буенча экспозиция оештырырга, физик һәм юридик затлардан тәкъдимнәр, киңәшләр һәм гаризалар кабул итәргә, адресы: Татарстан Республикасы, Нурлат ш., Совет ур., 117 й.;

5. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга https://nurlat.tatarstan.ru/.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Д.А. Ишкинеев